**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

12 май 2022 ел №18-01

Актаныш муниципаль районында
цифрлы трансформация үсеше стратегиясе турында

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Сираева Л. Р. Актаныш муниципаль районында цифрлы трансформация үсеше стратегиясе турында докладын тыңлаганнан соң, Актаныш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираеваның Актаныш муниципаль районында цифрлы трансформация үсеше стратегиясе турындагы докладын игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

2. Актаныш муниципаль районы башкарма комитетына Актаныш муниципаль районында цифрлы трансформация үсеше стратегиясен эшләргә һәм расларга (кушымта нигезендә).

3. Район Советының даими комиссияләрен Актаныш муниципаль районында цифрлы трансформация үсеше стратегиясенең куелган бурычларын планлы гамәлгә ашыру өчен җаваплы дип билгеләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Э.Н. Фәттахов

Актаныш муниципаль
район Советының
12.05.2022 ел, №18-01
карарына кушымта

Актаныш муниципаль районында цифрлы трансформация үсеше стратегиясе буенча куелган бурычлар

| № | Бурычлар | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1 | Актаныш муниципаль районында цифрлы трансформация үсеше стратегиясен тормышка ашыру буенча эшче төркем төзергә һәм аның составын расларга. | Габдулхаев И.И.<br>Ильясов Р.А. |
| 2 | Актаныш муниципаль районы башкарма комитетына Актаныш муниципаль районында цифрлаштыру технологияләрен үстерү һәм социаль-икътисади мәсьәләләрне чишүдә куллану турында стратегия эшләргә һәм расларга (кушымта нигезендә). | Ильясов Р.А.<br>Сираева Л.Р. |
| 3 | Районның социаль үсешендә халыкның яшәү сыйфатын яхшыртуда цифрлаштыру технологияләрен инструмент буларак актив кертергә һәм кулланырга, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән куллануны популярлаштырырга. | Ильясов Р.А.<br>Сираева Л.Р. |
| 4 | Актаныш районының икътисади үсешен цифрлашу технологияләре аша көчәйтергә. Сәнәгать мәйданчыгына резидентлар җәлеп итуне, маркетплейс инструментлары аркылы кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерергә. | Сираева Л.Р. |
| 5 | Актаныш районы уку йортларында балага тәрбия һәм белем бирүне үстерү өчен цифрлы инструментлардан, информацион һәм коммуникацион хезмәтләрдән торган цифрлы мохит булдырырга. | Нурлыева Л.Ф.<br>Шакирова Р.М. |
| 6 | Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге тармакларда цифрлы технологияләрне энергия, чимал экономиялэүдә, процессларны оптимальләштерүдә кулланып табыш алуны үстерергә. | Салимгараев Н.А. |
| 7 | Цифрлаштыру технологияләре аша район халкына медицина хезмәте күрсәтү юлын оптимальләштерергә, сыйфатын яхшыртырга. | Хаев А.Р. |